РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Большекляринского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Советская, 9,с. Большие Кляри, 422837
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 93064636, ОГРН 1061672003403
ИНН/КПП 1622004605/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Кариле**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 9,Олы Кариле авылы, 422837,
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 93064636, ОГРН 1061672003403
ИНН/КПП 1622004605/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**10 нчы сентябрь 2019 ел** **№32**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган документлар күчермәләрен һәм алардан өземтәләрне таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2018 елның 14 декабрендә кабул ителгән 10 номерлы карары белән расланган «Документлар күчермәсенә тугрылык һәм алардан өземтә алу буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон," Җирлекләрнең җирле администрацияләре башлыклары һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында инструкцияне раслау хакында” Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 06.06.2017 ел, № 97 “Муниципаль районнарның җирле администрацияләре башлыклары һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарының махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан» боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Башкарма комитетының 14.12.2018 ел, № 10 карары белән расланган “Документлар күчермәләренә тугрылык һәм алардан өземтә алу буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карарына

(алга таба – регламент) регламентның 2 бүлегендәге 2.9 пунктының икенче баганасын, түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:
“Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган”:

Баш тарту өчен нигезләр:

1) мондый гамәлне башкару Россия Федерациясе законнарына каршы килсә;

2) башка җирлекнең яисә муниципаль районның җирле үзидарәсе вазыйфаи заты тарафыннан (мирас милкен саклау буенча чаралар күрүгә карата һәм кирәк булган очракта алар белән идарә итү чаралары күрүгә карата) яисә нотариус тарафыннан гамәлгә ашырылырга тиеш;

3) нотариаль гамәл кылуны сорап эшкә сәләтсез граждан яисә кирәкле вәкаләтләре булмаган вәкил, яшәү урыны яисә җирлектә тору урыны буенча теркәлмәгән яисә торак пунктта урнашкан граждан мөрәҗәгать итсә;

4) юридик зат исеменнән эшләнелә торган килешү Уставта яки Нигезләмәдә күрсәтелгән максатларга каршы килсә;

5) сату-алу эше Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килмәсә;

6) нотариаль гамәл кылу өчен тапшырылган документлар Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килмәсә;

7) нотариаль гамәл кылу өчен бирелгән документларда бәян ителгән фактлар Россия Федерациясе законнары нигезендә раслау таләп ителгән очракта, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган очракта.».

2.Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:

-ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы,Пионер урамы, 1;

-ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин урамы, 43;

-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов урамы, 16 нчы йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Олы Кариле авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Г.Гарифуллин**